**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДЕРЖАВИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422620,Татарстан, с. Державино,
ул. Заббарова, д.39
тел: 3-45-20

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДЕРЖАВИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422620 Державино авылы,
Заббаров урамы, 39 нчы йорт,
тел: 3-45-20

**2023 елның 27 декабре** **74 номер**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге территориясендә урнашкан 16:24:060202:1008 кадастр номерлы җир участогы территориясендә коттедж поселогы урнаштыру өчен, планлаштыру һәм чикләү проектын раслау буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында.**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190 ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексына, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге территориясендә урнашкан 16:24:060202:1008 кадастр номерлы җир участогы территориясендә коттедж поселогы урнаштыру өчен, планлаштыру һәм чикләү проектын раслау буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1 Үткәрү датасын һәм вакытын – 2023 елның 26 гыйнварында 14.00 сәгатьтә.

2.2 Үткәрү урыны – Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасы: 422620, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Державино авылы, Җәббаров урамы, 39 йорт.

2.3 Коттедж поселогын урнаштыру өчен 16:24:060202:1008 кадастр номеры белән җир участогы территориясен планлаштыру һәм чикләү проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне, чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашуга гаризаларны 422620, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль район, Державино авылы, Җәббаров урамы, 39 йорт адресы буенча

урнашкан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге Башкарма комитетына җибәрергә мөмкин.
2.4 Чыгыш ясау хокукы белән җәмәгать тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты 2023 елның 24 гыйнварына кадәр.

3. Державино авыл җирлеге Башкарма комитетына:
- 2023 елның 28 декабренә кадәр әлеге карарны мәгълүмат стендында (Державино авылы, Җәббаров урамы, 39 йорт, Державино авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасы) игълан итәргә;
- 16:24:060202:1008 кадастр номерлы җир участогы территориясен коттедж поселогы урнаштыру өчен планлаштыру һәм чикләү проектын раслау буенча, ачык тыңлауларны, әлеге карар белән билгеләнгән срокларда, әзерләүне һәм үткәрүне оештырырга.

4. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга(халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.И.Камалиева